ИНСПЕКЦИЯ
ГОСУДАРСТВЕННОГО
СТРОИТЕЛЬНОГО НАДЗОРА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ДӘҮЛӘТ ТӨЗЕЛЕШЕН
КҮЗӘТҮ ИНСПЕКЦИЯСЕ

ПРИКАЗ　　　　　　　　　　　　　　　　БОЕРЫК

13.04.2015　　　　　　г. Казань　　　　　　№ 40

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен
күзәтү инспекциясенең норматив-хокукый актларына
һәм норматив-хокукый актларының проектларына
коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибен
раслау турында

2009 елның 17 июлендәге “Норматив-хокукый актларга һәм норматив-хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында”гы 172-ФЗ номерлы Федераль законны, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 24 декабрендәге “Аерым норматив-хокукый актларга һәм норматив-хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында” 883 номерлы карарын гамәлгә ашыру максатларында, шулай ук коррупциоген факторларны ачыклау һәм алга таба аларны бетерү максатларында,

**Б О Е Р А М:**

1. Кушымта булып килүче Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясенең норматив-хокукый актларына һәм норматив-хокукый актларының проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибен расларга.
2. Хокукый идарәнең юридик бүлегенә боерыкны дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгына җибәрергә.
3. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башлык вазифаларын башкаручы　　　　　　　　　　И.Ф. Сафиуллин

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясенең 2015 елның "13" апрель № 40 номерлы боерыгы белән расланды.

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясенең норматив-хокукый актларына һәм норматив-хокукый актларының проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү
ТӘРТИБЕ

I. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясенең норматив-хокукый актларына һәм норматив-хокукый актларының проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибе 2009 елның 17 июлендәге "Норматив-хокукый актларга һәм норматив-хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында"гы 172-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 26 февралендәге "Норматив-хокукый актларга һәм норматив-хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында" 96 номерлы карары белән расланган Норматив-хокукый актларга һәм норматив-хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү методикасы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 24 декабрендәге "Аерым норматив-хокукый актларга һәм норматив-хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында" 883 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясе (алга таба – Инспекция) тарафыннан эшләнә торган норматив-хокукый актларга һәм норматив-хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү һәм коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләрен исәпкә алу кагыйдәләрен билгели.

2. Коррупциягә каршы экспертиза әзерләнә торган норматив-хокукый актларның проектларына (алга таба – норматив-хокукый актларның проектлары) хокукый экспертиза ясаганда һәм Инспекция тарафыннан кабул ителгән норматив-хокукый актларны (алга таба – норматив-хокукый актлар) мониторинглаганда үткәрелә.

3. Норматив-хокукый актларда һәм норматив-хокукый актларның проектларында коррупциоген факторларны ачыклау һәм алга таба бетерү коррупциягә каршы экспертизаның максаты булып тора.

4. Көчен югалткан яки гамәлдән чыгарылган норматив-хокукый актларга карата коррупциягә каршы экспертиза үткәрелми.

## II. Норматив-хокукый актларга һәм норматив-хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибе

5. Коррупциягә каршы экспертиза Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 26 февралендәге 96 номерлы Карары белән расланган Норматив-хокукый актларга һәм норматив-хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү методикасы (алга таба – Методика) нигезендә үткәрелә.

6. Инспекция башлыгы Инспекциядә коррупциягә каршы экспертиза үткәрүгә җаваплы булган вазифаи затны (алга таба – вазифаи зат) билгели. Күрсәтелгән вазифаи зат шулай ук Инспекциянең коррупциягә каршы экспертизага бирелгән Норматив-хокукый актларны һәм норматив-хокукый актларны исәпкә алу журналын (алга таба – Журнал) алып бару өчен дә җаваплы була (1 кушымта).

7. Норматив-хокукый актны яисә норматив-хокукый актның проектын эшләгән структур бүлекчә (алга таба – эшләүче) аны вазифаи затка коррупциягә каршы экспертиза ясау өчен җибәрә, бу хакта җиткерелгән көнне үк Журналда чагылдырыла.

8. Норматив-хокукый актларга һәм норматив-хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү вакыты Журналда теркәгәннән соң ун көннән дә артып китә алмый.

9. Коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләре буенча вазифаи зат тарафыннан бәяләмә әзерләнә һәм имзалана.

Коррупциоген факторлар булу турындагы бәяләмәдә (2 кушымта) коррупциягә каршы үткәрелгән экспертиза барышында ачыкланган коррупциоген факторлар чагылдырыла һәм аларны бетерү ысуллары тәкъдим ителә.

Норматив-хокукый актларда һәм норматив-хокукый актларның проектларында коррупциоген факторлар булмаган очракта коррупциоген факторлар юклыгы турында бәяләмә рәсмиләштерелә (3 кушымта), ул эшләүчегә җибәрелә.

10. Әгәр дә экспертизага җибәрелгән норматив-хокукый актның проектында коррупциоген факторлар булмаса, эшләүче, коррупциоген факторлар юклыгы турындагы бәяләмәне алгач, норматив-хокукый проект актын структур бүлекчәләрнең кызыксынган җитәкчеләренең визалары белән бергә имза салу өчен башлыкка җибәрә.

11. Әгәр дә норматив-хокукый актта коррупциоген факторлар ачыкланса, эшләүче, бәяләмәне алгач, Инспекция башлыгы белән килештереп, аңа үзгәрешләр кертү яки аны көчен югалткан дип тану кирәклеге хакында карар кабул итә.

Эшләүче, өч көн эчендә, ачыкланган коррупциоген факторларны бетерү максатында үзгәрешләр кертү турында норматив-хокукый акт проекты яки норматив-хокукый актны көчен югалткан дип тану турында

проект әзерли һәм аны вазифаи затка коррупциягә каршы экспертизага җибәрә.

12. Әгәр дә экспертизага җибәрелгән норматив-хокукый акт проектында коррупциоген факторлар ачыкланса, эшләүче, коррупциоген факторлар булу турындагы бәяләмәне алгач, өч көн дәвамында җитешсезлекләрне бетерергә һәм эшләнеп беткән акт проектын кабат коррупциягә каршы экспертиза үткәрү өчен вазифаи затка җибәрергә тиеш.

13. Норматив-хокукый актларга һәм норматив-хокукый актларның проектларына кабат коррупциягә каршы экспертиза үткәрү вакыты өч көннән дә артмый.

14. Коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләре Журналда чагылдырыла.

## IV. Норматив-хокукый актларга һәм норматив-хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү тәртибе

14. Инспекциянең рәсми төстә басылып чыккан норматив-хокукый актлары һәм Инспекция тарафыннан эшләнә торган, “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең рәсми порталында урнаштырылган норматив-хокукый актларның проектлары коррупциягә каршы бәйсез экспертиза объектлары булып тора.

15. Дәүләт серен яки конфиденциаль характердагы белешмәләрне үз эченә алучы мәгълүматлары булган норматив-хокукый актларга, норматив-хокукый актларның проектларына карата коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрелми.

16. Норматив-хокукый актның проектына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү өчен эшләүче аны, аларны юридик бүлек карап тикшерүенә җибәргән көнгә тәңгәл килүче эш көне дәвамында норматив-хокукый актларны урнаштыру өчен, Инспекция башлыгының боерыгы нигезендә билгеләнгән җаваплы затка (алга таба – Җаваплы зат) җибәрә.

17. Эшләүчедән норматив-хокукый актның проектын алу көненә тәңгәл килүче эш көне дәвамында Җаваплы зат аларны Инспекциянең “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыра.

18. Аларга коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү өчен норматив-хокукый актларның проектларын урнаштырганда Җаваплы зат эксперт бәяләмәләрен җибәрү өчен адресны (шул исәптән электрон почта адресын), шулай ук коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмәләрне кабул итә башлау һәм кабул итүне тәмамлау вакытларын күрсәтә.

19. Норматив-хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү вакыты аларны “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштырган көннән башлап биш эш көне тәшкил итә.

20. Норматив-хокукый актны, норматив-хокукый актның проектын эшләүче коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча килеп ирешкән бәяләмәне (алга таба – бәяләмә) карап тикшерә һәм алганнан соң 15 көнлек срокта дәлилләнгән җавапны, бәяләмәдә ачыкланган коррупциоген факторларны бетерү ысулы турында тәкъдимнәр булмаган очраклардан тыш, коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәргән юридик яки физик затка җибәрә.

21. Норматив-хокукый актка, норматив-хокукый актның проектына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәргәндә ачыкланган коррупциоген факторлар эшләүче тарафыннан ун көн эчендә бетерелә.

22. Кисәтүләрне бетергәч һәм коррупциягә каршы бәйсез экспертиза бәяләмәсендәге тәкъдимнәрне исәпкә алганнан соң, коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча ирештерелгән бәяләмәләрне теркәп, эшләүче норматив-хокукый акт проектын вазифаи затка яңадан карап тикшерү өчен бирә. Яңадан карап тикшерү өч көн эчендә башкарыла.

23. Әгәр дә норматив-хокукый актта коррупциоген факторлар ачыкланса, эшләүче норматив-хокукый актка үзгәрешләр кертү яки аны көчен югалткан дип тану буенча чаралар күрә.

24. Эшләүче норматив-хокукый актларда яки норматив-хокукый актларның проектларында коррупциоген факторлар булуны таныклый торган коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре белән риза булмаган очракта, законнарда билгеләнгән тәртиптә эшләүче күрсәтелгән норматив-хокукый актларны, норматив-хокукый актларның проектларын, коррупциягә каршы бәйсез экспертиза бәяләмәләрен һәм үзенең ризасызлыгын дәлилләүче аңлатма язуын теркәп, коррупциягә каршы экспертиза үткәрү өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрә.

25. Эшләүче үзе тарафыннан эшләнгән, закон чыгару инициативасы тәртибендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан Россия Федерациясе Федераль Җыелышының Дәүләт Думасына кертелүче федераль законнарның проектларында, Татарстан Республикасы законнары проектларында, Татарстан Республикасы Президенты указлары проектларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары проектларында коррупциоген факторлар булуны таныклаучы коррупциягә каршы, шул исәптән бәйсез экспертиза нәтиҗәләре белән риза булмаган очракта, аталган норматив-хокукый актларның проектларын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә, карап тикшерү өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тапшыра.

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү
Инспекциясенең норматив-хокукый актларына һәм
норматив-хокукый актларының проектларына
коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибенә
1 кушымта

Коррупциягә каршы экспертизага килеп ирешкән норматив-хокукый актларны һәм норматив-хокукый актларның проектларын исәпкә алу

ЖУРНАЛЫ

| № | Актның (акт проекты-ның) экспертиза га бире-лү көне | Актны (акт проектын) эшләүче структур бүлекчә исеме | Актның (акт проекты-ның) исеме | Экспер-тиза үткәрү вакыты | Коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәсе | Структур бүлекчәнең белгече тарафыннан бәяләмәне алу көне һәм аның имзасы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү
Инспекциясенең норматив-хокукый актларына һәм
норматив-хокукый актларының проектларына
коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибенә
2 кушымта

**Коррупциоген факторлар булу турында бәяләмә**

________________________________________________________________

(норматив-хокукый актның яки норматив-хокукый акт проектының исеме)

2009 елның 17 июлендәге "Норматив-хокукый актларга һәм норматив-хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү турында" 172-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 26 февралендәге "Норматив-хокукый актларның һәм норматив-хокукый актлар проектларының коррупциягә каршы экспертизасы турында" 96 номерлы Карары белән расланган Норматив-хокукый актларга һәм норматив-хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү методикасы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясе тарафыннан

________________________________________________________________

(норматив-хокукый актның яки норматив-хокукый акт проектының исеме)

карата коррупциоген факторларны ачыклау һәм алга таба аларны бетерү максатында коррупциягә каршы экспертиза үткәрелде

Тапшырылган____________________________________________________

(норматив-хокукый актның яки норматив-хокукый акт проектының исеме)

Коррупциоген факторлар чыкланды __________________________________

(коррупциоген факторларның төрләре күрсәтелә)

________________________________________________________________

Ачыкланган коррупциоген факторларны бетерү максатларында түбәндәгеләр тәкъдим ителә

________________________________________________________________

(коррупциоген факторларны бетерү ысулы күрсәтелә)

__________________________ __________ ____________________ ________

(вазифа исеме) (имза) (инициаллар, фамилия) (дата)

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү
Инспекциясенең норматив-хокукый актларына һәм
норматив-хокукый актларының проектларына
коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибенә
3 кушымта

**Коррупциоген факторлар юклыгы турында бәяләмә**

________________________________________________________________
(норматив-хокукый актның яки норматив-хокукый акт проектының исеме)

2009 елның 17 июлендәге “Норматив-хокукый актларга һәм норматив-хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү турында” 172-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 26 февралендәге “Норматив-хокукый актларның һәм норматив-хокукый актлар проектларының коррупциягә каршы экспертизасы турында” 96 номерлы Карары белән расланган Норматив-хокукый актларга һәм норматив-хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү методикасы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясе тарафыннан

________________________________________________________________
(норматив-хокукый актның яки норматив-хокукый акт проектының исеме)
карата коррупциоген факторларны ачыклау һәм алга таба аларны бетерү максатында коррупциягә каршы экспертиза үткәрелде

Тапшырылган__________________________________________________
(норматив-хокукый актның яки норматив-хокукый акт проектының исеме)

коррупциоген факторлар ачыкланмады.

| ________________ | ________ | ________________ | ________ |
|---|---|---|---|
| (вазифа исеме) | (имза) | (инициаллар, фамилия) | (дата) |